

Мордовиядә агросәнәгать комплексы очен ин моһим вакыйгаларнын берсе - сорv буенча VIII Россия Ачык чемпионаты булды.
Россия чемпионаты кысаларында профильле уку йортлары укучылары арасында жир сорv буенча республика конкурсы узды. Финалда ин яхшы сабанчы булу хокукы очен Юлия Янбухтина корәште һәм жинде.
Темниково районынын Татар Акашево авылында туган кыз I урынны яулады! Республика сабанчылар конкурсына йомгак ясау конендә Юлиягә икеләтә бәйрәм булды: иртәдән рес-публика башлыгы Владимир Волков аны конкурс жинvчесе буларак котлады, ә берничә сәгатьтән сон Республика йортында ветеринария фельдшеры белгечлеге буенча Краснослободск аграр колледжын бик яхшы билгеләренә тәмамлаган буларак диплом тапшырды.       - Доресен әйткәндә, мин vзем жинәрмен дип котмәгән идем, - ди «Темников яналыклары» газетасына биргән интервьюсында. Әмма әти - әниләр мина ышанды. Әтием мине ин яхшы сабанчы булачакмын, дип тә әйтте (Янбухтиннарнын шәхси хужалыгында жир эшкәртv очен тракторы белән комбаины да бар. Юлия балачакта ук техниканы бик яраткан һәм йорткән. Анын экскаваторчы категориясе белән тракторчы-машинист хокукы да бар). Мина зур һәм кочле авыл хужалыгы техникасы белән идарә итv ошый. Димәк, хоббием мина жинv китерде. Мин хәтта коллияткә дә механизатор булып керергә теләгән идем, тик кинәшләргә колак салдым. Укуымны дәвам итәргә уйлыйм, шуна Н.П.Огарев исемендәге МГУнын ветеринария факультетына укырга керергә ниятлим.
Ярышта Юлия Янбухтина тест нәтижәләре буенча сайлап алу турын узды һәм егетләр белән беррәттән зур ярышларда катнашып жинде. Башта бәйге колледж эчендә vткәрелде. Имтихандагы кебек барысы да: теория, аннары МТЗ-82 практикасы. МТЗ-12-21дә барлыгы жиде ир бала һәм оч кыз Мордовиянен ин яхшы яшь жир сорvчесе булу хокукы очен корәште. Барлык этаплары нәтижәләре буенча Юлия шунда ук лидерлыкка чыкты. Шулай итеп коллиятне тәмамлаган кыз һәм булачак ветеринария табибы жинvче булды.
Әйтеп китәргә кирәк, Чемпионат ярышларында илнен 45 тобәгеннән 58 жир кишәрлеге vз осталыкларын кvрсәтте. Пенза олкәсеннән Сергей Захаров жинvче булды, ул Россия чемпионы исемен алды һәм топ приз - Киров К- 424 тракторы белән бvләкләнде. Илнен ин яхшы сабанчысы АКШта августта узачак Доньякvләм чемпионатында да Россия данын яклаячак.